ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октября, д.1Б,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Октябрь урамы, 1Б йорт,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 6-23-33, факс:6-25-28, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 10** **06 октябрь 2021 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Бэйрэкэ авыл җирлегендә коррупция
фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгате
тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

2006 елның 2 маендагы «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы 59-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсе, 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 21 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бэйрэкэ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бэйрэкэ авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бэйрэкэ авыл җирлегендә коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгате тәртибе турында Нигезләмәне (кушымта) расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Бэйрэкэ авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга мөмкин: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Бэйрэкэ авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина